# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Татар Наратлысы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**2023 елның 18 октябре** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Татар Наратлы торак пунктында гражданнар җыены **карар кабул итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Татар Наратлы торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1.Автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән Татар Наратлысы торак пунктында объектны техник паспортлаштыру;

2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зеленодольск муниципаль районы
Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы Г.Ф.Семахина